**СОВЕТ БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
42275 Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Большой Битаман, ул.Московская, д.2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур,2В

Тел./факс: +7(84365) 62-847, e-mail:Bbit.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**13 ноября 2023 г.** **№75**

**Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендә 9 номерлы “Физик затларның милке” турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 9 номерлы карарына (советның 25.12.2018 № 114, 28.11.2022 № 59, 21.09.2023 № 69 карары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләр:

3 нче пунктның 3.2 пунктчасы түбәндәге редакциядә китерелсен:

"3.2 Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге территориясендә мөлкәткә ия булган Россия Федерациясе физик затларын мөлкәткә салым түләүдән азат итәргә.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлыбелән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Ф.Ю.Закиров